**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**Сарман авыл жирлеге**
**423350 Сарман авылы, Ленин ур.,52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**

**E - mail: Sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**423350 с. Сарманово, ул.Ленина,52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @tatar.ru**
ИНН/КПП 16360012661/163601001

---

РЕШЕНИЕ КАРАР
22 ноября 2017 года № 23

Татарстан Республикасы Сарман районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр кертү турында карары проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 78-80 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы Карары проектын(1 нче кушымта) халык алдында тыңлауларга чыгарырга.

2.Раслау:

- Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе (2 нче кушымта);

- Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы проект буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе (13 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Сарман

муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү буенча эшче төркем төзергә;:

1.Агелтдинов Зөбәер Зәйнетдин улы-төркем җитәкчесе

2. Хамматов Радик Зөлфәт улы-төркем әгъзасы

3.Сәлимгәрәев Равил Фазыл улы-төркем әгъзасы

4.Мөхәммәдиев Рөстәм Әхнәф улы-төркем әгъзасы

5.Ахкамова Илсөяр Госман кызы-төркем әгъзасы

4.Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар 11 декабрь көнне 15.00 сәгатьтә Сарман авылы, Ленин урамы, 28 нче йорт адресы буенча киноучреждение бинасының конференц-залында үткәрергә.

5. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" PRAVO.TATARSTAN.RU (Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Сарман авыл җирлеге

Сарман Муниципаль Районы Советы Рәисе Ф. М. Хөснуллин